**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Түйкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Түйкә авылы № 91-42 30 март 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлегенең 2012 елның 20 апрелендәге 36 номерлы карары белән расланган Түйкә авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (18.02.2015 №103, 10.09.2015 № 133, 09.03.2016 № 27-10 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 октябрендәге 299-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль законнарны үтәү йөзеннән

Түйкә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлегенең 2012 елның 20 апрелендәге 36 номерлы карары белән расланган Түйкә авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә (18.02.2015 №103, 10.09.2015 № 133, 09.03.2016 № 27-10 карарлар редакциясендә түбәндәге редакциядә 1.4 пунктын бәян итеп, үзгәреш кертергә:

««1.4. Халык тыңлауларына мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1)җирлек уставы проекты, шулай ук гамәлдәге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, Уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (Устава) яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш;

2)җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3)җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4)«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 06.10.2003 N 131-ФЗ номерлы 13 статьясы нигезендә җирлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында белдерелгән җирлек халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түйкә авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.Р.Закирова